# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турында**

Табигать һәм аның байлыклары Татарстан Республикасы халкының байлыгы, кешенең тереклек һәм тормыш итү тирәлеге, тотрыклы социаль-икътисадый үсешенең табигый нигезе була.

Әлеге Закон кешеләрнең гомере һәм сәламәтлеге өчен уңайлы әйләнә-тирә табигать мохитенә хокукын яклауны тәэмин итәргә, бүгенге һәм киләчәк буыннар мәнфәгатьләрендә әйләнә-тирә табигать мохитенең хокукый, икътисадый һәм социаль нигезләрен барлыкка китерүдә ярдәм итәргә омтыла һәм экологик иминлекне һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итүгә юнәлдерелә.

## I б ү л е к

## Гомуми нигезләмәләр

### 1 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу

Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләр Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка законнар белән җайга салына.

### 2 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турында Татарстан Республикасы законнарының бурычлары

Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан

110



Республикасы законнарының бурычлары әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, экологик иминлек һәм гражданнарның хокукларын яклауны тәэмин итү, республиканың табигый байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану, хәзерге һәм киләчәк буыннар мәнфәгатьләрендә әйләнә-тирә табигать мохитен савыктыру һәм аның сыйфатын яхшырту максатларында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салудан гыйбарәт.

3 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклауның төп принциплары

Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау түбәндәге принципларга нигезләнеп башкарыла:

- табигать мохитен, табигый байлыклар базасын, табигый системаларның һәм кешенең тормыш эшчәнлеген яклау;

- табигать мохите халәтен начарайтырлык карарларны, кызыксынучы һәм үз мәнфәгатьләренә кагылучы якларга беренче чиратта бу хакта хәбәр итеп, ачык рәвештә кабул итәрлек тәртип тәэмин итү, аларда дөрес кабул ителмәгән карарларны яңадан карау һәм төзәтү өчен гадел һәм тигез мөмкинлекләр каралырга тиеш;

- Татарстан Республикасы гражданнарының хәзерге һәм киләчәк буынына, чит ил гражданнарына һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданлыксыз затларга имин, сәламәт һәм сыйфатлы тормыш тәэмин итү өчен законнар нигезендә тигез мөмкинлекләр булдыру;

- социаль-икътисадый система һәм әйләнә-тирә табигать мохите халәтендәге үзгәрешләр турындагы мәгълүматлар системаларының нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү;

- хуҗалык эшчәнлеге башкарганда гражданнарның экологик мәнфәгатьләре белән җәмгыятьнең үсеш зарурлыгының тәңгәллеге;

- табигатьтән гомуми файдалануның бушлай булуы һәм махсус файдалануның түләүле булуы, әйләнә-тирә табигать мохитенә китерелгән зыянны түләттерү, законнар нигезендә табигатьтән файдалануны лицензияләү һәм квоталау һәм хуҗалык эшчәнлегенең әйләнә-тирә табигать мохитенә тәэсир итү дәрәҗәсен нормалаштыру юлы белән Татарстан Республикасының табигый байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану;

- табигатьне саклау турындагы законнарның таләпләрен үтәү, аларны бозган өчен җаваплылыкның котылгысыз булуы;

- табигатьне саклауга кагылышлы бурычларны хәл иткәндә җәмәгать оешмалары һәм халык белән тыгыз элемтәдә булу, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек.

<u>4 статья.</u> Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау объектлары

1. Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәгеләр пычранудан, бозылудан, җимерелүдән, кимetелүдән, юкка чыгарылудан һәм башкача нәтиҗәсез һәм хуҗалыксыз файдаланудан саклана:

- җир, җир асты байлыклары, урманнар, сулар, атмосфера һавасы, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының һәр төре, типик һәм сирәк очраучы ландшафтлар, курорт зоналары, махсус саклана торган табигать территорияләре, климат, атмосфераның озон катламы һәм, табигый экологик системаларның һәм биосфераның компонентлары буларак, табигатьнең башка объектлары.

2. Кешеләр сәламәтлеге һәм гомере хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төр эшчәнлекнең тискәре йогынтысыннан сакланырга тиеш.

<u>5 статья.</u> Күпләп юк итү коралын читтән кертүне, җитештерүне, саклауны һәм күмүне тыю

Татарстан Республикасы территориясендә күпләп юк итү коралын, шулай ук аның компонентларын һәм аны зарарсызландыру калдыкларын читтән кертү, җитештерү, саклау һәм күмү тыела. Татарстан Республикасы территориясе аша химик коралны юк итү урыннарына транзит ташулар бары тик Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты ризалыгы белән генә башкарылырга мөмкин.

<u>6 статья.</u> Татарстан Республикасының экологик программалары

1. Әйләнә-тирә табигать мохитенең сыйфатын һәм аны савыктыруны тәэмин итү буенча нәтиҗәле һәм максатчыл эшчәнлекне оештыру йөзеннән, Татарстан Республикасының дәүләт программа-

сы, шулай ук шәһәрләрнең һәм районнарның экологик программалары әзерләнә һәм гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт экологик программаларын төзү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан, районнарның һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең экологик программаларын төзү тәртибе дәүләт идарәсенең җирле органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

## II бүлек

## Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә гражданнарның хокуклары

7 статья. Гражданнарның сыйфатлы әйләнә-тирә табигать мохитенә хокукы

Татарстан Республикасының һәр гражданы һәм аның территориясендә яшәүче затлар сыйфатлы әйләнә-тирә табигать мохитенә хаклы.

Бу хокук дәүләт тарафыннан тәэмин ителә һәм түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге закон проектларын һәм башка хокукый-норматив актларны караганда катнашу;
- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, табигый байлыклардан нәтиҗәле һәм комплекслы файдалану өлкәсендәге гамәлләрне әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашу;
- табигатьтән гомуми файдалану һәм махсус файдалану;
- табигатьне саклау буенча җәмәгать оешмаларына берләшү;
- әйләнә-тирә табигать мохитенең халәте һәм халыкның сәламәтлеге турында тулы һәм хак мәгълүмат алу;
- экологик җәмәгать экспертизасын үткәргәндә катнашу;
- әйләнә-тирә табигать мохитен пычрату аркасында гражданнар сәламәтлегенә һәм мал-мөлкәтенә китерелгән зыянны түләттерү;
- эшчәнлекләре аркасында гражданнар сәламәтлегенә, мөлкәтенә зыян китерүче предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларының хокукка каршы гамәлләренә ка-

рата шикаять белдерү;

- табигый байлыкларны тотрыклы итү, яңадан торгызу һәм әйләнә-тирә табигать мохитенең халәтен яхшырту гамәлләрен башкару;

- иминләштерүнең төрле төрләре;

- министрлыкларга, ведомстволарга, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы законнарның таләпләрен һичшиксез үтәүләренең, иҗтимагый экологик хәрәкәтләргә һәм оешмаларга (берләшмәләргә) табигатьне саклау эшчәнлекләрен башкарганда ярдәм күрсәтүләренең мәҗбүрилеге;

- әйләнә-тирә табигать мохитенең мониторингын уздыру;

- җәмәгать оешмаларының (берләшмәләренең) һәм гражданнарның әйләнә-тирә табигать мохитен саклау эшчәнлегендә катнашулары;

- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы законнарның үтәлешен дәүләт тарафыннан тикшереп тору;

- әйләнә-тирә табигать мохитен пычрату аркасында гражданнар сәламәтлегенә һәм мал-мөлкәтенә китерелгән зыянны хөкем тәртибендә түләттерү, шул исәптән һәлакәтләр һәм бәла-казалар аркасында килеп чыккан күренешләрне бетерү;

- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык билгеләү.

2. Гражданнарның сыйфатлы әйләнә-тирә табигать мохитенә булган хокукларын гамәлгә ашыруга комачаулаучы эшчәнлек законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатылырга тиеш.

## III бүлек

## Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының вәкаләтләре

<u>8 статья.</u> Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре

Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан

114



Республикасы Дәүләт Советы карамагына түбәндәгеләр керә:

- Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча законнар кабул итү һәм аларга үзгәрешләр кертү;
- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләү;
- дәүләтнең экологик программасын раслау;
- табигатьне саклау турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору;
- Татарстан Республикасы Экология фондының эшчәнлеген тикшереп тору.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигый байлыклардан файдалану, Татарстан Республикасы территориясендә экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсенә кагылышлы башка мәсьәләләрне дә карый ала.

9 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының вәкаләтләре

Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты:

- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм савыктыру табигый байлыклардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә комплекслы һәм максатчыл дәүләт программаларын эзерли һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына тәкъдим итә;
- табигый байлыклардан файдалануның, әйләнә-тирә табигать мохитенә чыгарып ташланучы һәм агызып чыгарылучы пычраткыч матдәләрнең, калдыкларны урнаштыруның экологик нормативларын, лимитларын әзерләү тәртибен раслый;
- әйләнә-тирә табигать мохитен пычраткан, калдыклар урнаштырган, башка зарарлы йогынтылар өчен түләүләрнең нормативларын билгели;
- дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә халык хуҗалыгының эре объектларын урнаштыру турында карарлар кабул итә;
- республика күләмендә әһәмияткә ия булган табигый тыюлык фонды территорияләрен һәм объектларын оештыру турында карарлар кабул итә;

- Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигый байлыклар өлкәсендә министрлыкларның һәм ведомстволарның эшен берләштерә һәм аңа юнәлеш бирә;

- табигый байлыкларны исәпкә алу һәм бәяләү тәртибен, шулай ук табигый байлыкларның кадастрын алып бару тәртибен билгели;

- территория участокларын гадәттән тыш вәзгыять һәм бәла-каза зоналары дип игълан итү буенча карарлар кабул итү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Президентына кертә;

- табигый байлыклардан һәм әйләнә-тирә табигать мохитеннән файдалану тәртибен билгели;

- аеруча кыйммәтле табигый байлыкларның исемлеген һәм аларны чыгару тәртибен раслый;

- республика күләмендә әһәмияткә ия булган табигый байлыкларның запасларын раслый;

- хайваннар (шул исәптән балык запаслары да) һәм үсемлекләр дөньясыннан файдалануга квоталар билгели;

- Татарстан Республикасының Экология фондын төзү һәм аннан файдалану тәртибен билгели;

- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе арасында, шулай ук Россия Федерациясенең башка субъектлары белән килеп чыккан мәсьәләләрне карау һәм хәл итү эшләрендә катнашу өчен вәкилләр билгеләп куя;

- әйләнә-тирә табигать мохитенең халәте һәм аны савыктыру гамәлләре турында дәүләтнең еллык нотыгын әзерләүне һәм таратуны оештыра;

- гражданнарга өзлексез рәвештә экологик белем бирү һәм тәрбияләү системасын оештыра;

- Татарстан Республикасы гражданнарын экологик мәгълүмат белән тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигый байлыклардан файдалану өлкәсендә әлеге Законда билгеләнгән башка вәкаләтләрне дә үтәргә мөмкин.

10 статья. Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы вәкаләтләре

1. Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы карамагына түбәндәгеләр керә:

- Татарстан Республикасында табигатьтән файдалануны һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны җайга салу өлкәсендәге эшчәнлеккә идарә итү, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклардан файдалану мәсьәләләре буенча бердәм фәнни-техник сәясәт уздыру;

- әйләнә-тирә табигать мохитенә антропоген йогынтыларның мөмкин нормаларын һәм нормативларын билгеләү, табигый байлыкларның һәр төрен чыгаруның, куллануның һәм җитештерүгә җәлеп итүнең фәнни нигезләнгән квоталарын һәм лимитларын билгеләү, табигатьтән файдалануны һәм төрле калдыкларны күмүгә (бер урынга җыеп куюга) рөхсәт бирү (лицензияләү);

- әйләнә-тирә мохитне саклау, табигатьтән файдалану, экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә инструктив һәм норматив-ысулый нигез барлыкка китерү;

- экологик мониторингның бердәм дәүләт системасын оештыру;

- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын башкару;

- Татарстан Республикасының табигый тыюлыклар фондына идарә итү, Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару, табигый тыюлыклар эшен оештыру;

- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, табигый байлыклардан файдалану һәм экологик иминлек тәэмин итү өлкәсендә халыкара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

- табигатьне саклау турындагы законнарны бозган очракта, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшчәнлекләре нәтиҗәләре шәхескә, гражданнар (яисә юридик затлар) милкәтенә зарар китерсә, аларның эшчәнлекләрен чикләү, туктатып тору яисә бөтенләй туктату турындагы мәсьәләләрне карау өчен судка җибәрү хакында карарлар кабул итү.

2. Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохитен һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы әйләнә-тирә табигать мохитенең халәте һәм табигый байлыкларның саклнышы өчен җаваплы була.

11 статья. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнарының вәкаләтләре

1. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары карамагына түбәндәгеләр керә:

- табигый байлыкларның аерым төрләреннән файдалануны җайга салу;
- табигый байлыкларның аерым төрләреннән, табигать объектларыннан һәм табигать комплексларыннан файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп тору.

2. Табигый байлыкларның аерым төрләреннән файдалануны һәм аларны саклауны җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары һәм аларның территория органнары әлеге табигый байлыкларның халәте өчен җаваплы булалар.

12 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары вәкаләтләре

Халык депутатларының җирле Советлары карамагына түбәндәгеләр керә:

- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне тәэмин итү;
- экологик программаны эшләү һәм раслау;
- табигатьне саклау турындагы законнарның һәм тиешле экологик программаларның үтәлешен тикшереп тору;
- табигый тыюлык фонды объектларын саклау гамәлләрен тәэмин итү;
- экологик экспертиза үткәрү турында карарлар кабул итү;

- законнар нигезендә табигый байлыкларны бирү, кире алу;
- Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.

2. Җирле хакимиятләр карамагына түбәндәгеләр керә:
- нинди ведомствога буйсынуларына һәм милек рәвешләренә карамастан, табигый байлыклардан файдалануны һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклауны тикшереп тору;
- предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның һәм гражданнарның табигатьне саклау буенча нәтиҗәле эшчәнлекләрен икътисадый хуплау гамәлләрен башкару;
- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау;
- экологик программаларның проектларын эзерләү;
- экологик иминлек таләпләрен исәпкә алып, шәһәр төзелеше документларын раслау;
- табигатьне саклау һәм табигый байлыклардан нәтиҗәле файдалану гамәлләрен эзерләү һәм башкару;
- үзләренә буйсынучы предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге эшчәнлекләрен җайга салу һәм тикшереп тору;
- иҗтимагый экологик экспертизалар үткәрүгә ярдәм итү.

## IV бүлек

## Табигатьтән файдалануны һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны икътисадый җайга салу

### <u>13 статья.</u> Табигатьтән файдалануны һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны икътисадый җайга салу

Татарстан Республикасында табигатьтән файдалануны һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны икътисадый җайга салу түбәндәгеләрдән гыйбарәт:
- табигатьне саклау гамәлләрен төрле финанслау чыганаклары исәбеннән башкаруны тәэмин итү;
- табигый байлыклардан файдалануның, әйләнә-тирә табигать мохитенә чыгарып ташланылучы һәм агызып чыгарылучы пычраткыч матдәләрнең, калдыкларны барлыкка китерүнең һәм урнаштыруның

димитларын, түләү нормативларын һәм шулар нигезендә табигый байлыклардан файдалану өчен һәм аларны торгызуга түләүләр;

- предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм граждannar аз калдыклы һәм табигый байлыкларны саклап калырлык технологияләрне һәм энергиянең традицион булмаган төрләрен файдалануга керткәндә, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча башка нәтиҗәле гамәлләр башкарганда, аларга салым һәм кредит ташламалары, башка ташламалар бирү;

- әйләнә-тирә табигать мохитенә һәм кешеләр сәламәтлегенә китерелгән зыянны билгеләнгән тәртиптә һәм законнар нигезендәге башка гамәлләр аша түләттерү.

<u>14 статья.</u> Табигый байлыкларны исәпкә алу һәм социаль-икътисадый бәяләү

1. Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигый байлыклар өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органнары, дәүләт статистикасы органнары һәм табигатьтән файдаланучылар белән бергә, табигый байлыкларны һәм икенчел чималны сан һәм сыйфат ягыннан исәпкә алалар, аларның социаль-икътисадый әһәмиятен билгелиләр.

2. Дәүләтнең экологик-икътисадый кадастрын, җир, су, урман кадастрларын, җир асты байлыклары, хайваннар дөньясы, махсус саклanyлучы территорияләрнең һәм объектларның кадастрларын алып бару Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигый байлыклар өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органнарына йөкләнә.

<u>15 статья.</u> Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча экологик программаларны һәм гамәлләрне планлаштыру, финанслау һәм матди-техник тәэмин итү

1. Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигатьтән файдалану гамәлләрен планлаштыру, кайбер территорияләрнең табигый байлыклары мөмкинчелеген исәпкә алып, дәүләт экология программасы нигезендә социаль-икътисадый үсеш күзаллаулары һәм программалары составында гамәлгә ашыры-

ла.

2. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә территория планлаштыруы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары тарафыннан башкарыла.

3. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге тармак планлаштыруы республика һәм территория планлаштыруы күрсәткечләре нигезендә законнар буенча министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Экологик программалар һәм гамәлләр түбәндәгеләр исәбеннән финанслана:

- Татарстан Республикасының республика бюджеты, җирле бюджетлар;

- милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар;

- Татарстан Республикасының Экология фонды;

- минераль байлыклар запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча Татарстан Республикасының бюджеттан тыш фонды;

- банкларның кредитлары;

- гражданнардан, чит илләрнең юридик һәм физик затларыннан килгән ирекле иганәләр, шулай ук законнар нигезендә башка чыганаклар.

5. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча экологик программаларны һәм гамәлләрне финанслау Татарстан Республикасының республика бюджетындагы дәүләт һәм җирле бюджетларындагы аерым статьядан башкарыла.

16 статья. Табигатьтән файдалану төрләре һәм шартлары

1. Татарстан Республикасында табигый байлыклардан файдалану табигатьтән гомуми һәм махсус файдалану тәртибендә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы гражданнарының һәм аның территориясендә яшәүче башка затларның, аларга табигый байлыкларны беркетмичә генә, табигатьтән гомуми файдалануы түләүсез була.

Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохитен һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, дәүләт идарәсенең җирле органнары кайбер очракларда табигатьтән гомуми файдала-

нуның бүтән шартларын да билгеләргә мөмкин.

3. Хуҗалык эшчәнлеген башкару өчен табигатьтән махсус файдалану тәртибендә табигый байлыклар шартнамә һәм лицензия нигезендә файдалануга (шул исәптән арендага) тапшырылырга мөмкин.

4. Табигатьтән махсус файдалануның төп шартлары табигый байлыклардан файдаланган өчен, әйләнә-тирә табигать мохитенә пычраткыч матдәләр чыгарып ташлаган һәм агызып чыгарган өчен, җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китергән һәм урнаштырган өчен табигый байлыклардан файдаланучы яисә табигать мохитенә йогынты ясаучы предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга һәм гражданнарга, чит илләрнең юридик һәм физик затларына түләүләр билгеләүдән гыйбарәт.

5. Табигатьтән махсус файдаланган өчен түләү кертү табигатьтән файдаланучыны әйләнә-тирә табигать мохитен саклау гамәлләрен үтәүдән һәм табигатьне саклау турындагы законнарны бозу аркасында китерелгән зыянны түләүдән азат итми.

6. Байлыкларны табигатьтән махсус файдалануга тапшыру һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча экологик таләпләрне үтәү табигатьне саклау турындагы законнар һәм табигатьтән файдалану турындагы шартнамә белән билгеләнә.

<u>17 статья.</u> Табигатьтән комплекслы файдалану шартнамәсе һәм лицензиясе

1. Табигатьтән комплекслы файдалану турындагы шартнамә табигатьтән файдаланучы белән җирле хакимиятләр арасында күз алдында тотылучы хуҗалык эшчәнлегенә һәм башка төр эшчәнлеккә ясалган экологик экспертиза һәм табигатьтән комплекслы файдалану өчен бирелгән лицензия нигезендә төзелә.

2. Табигатьтән комплекслы файдалану өчен лицензия табигатьтән файдаланучыга әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан табигый байлыкларның кайбер төрләреннән файдалану өчен бирелүче рөхсәтләр нигезендә Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы тарафыннан түбәндәгеләр күрсәткән килеш бирелә:

- табигый байлыклардан файдалану буенча хуҗалык эшчәнле-

генең, житештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерүнең һәм урнаштыруның төрләре, күләмнәре һәм лимитлары;

- табигый байлыклардан файдалану рөхсәт ителгән очракларда, житештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү һәм файдалануның экологик таләпләре;

- бу таләпләрне үтәмәү аркасында килеп чыккан күренешләр.

3. Табигатьтән комплекслы файдалану хокукы табигатьтән комплекслы файдалану лицензиясе алынган көннән барлыкка килә.

18 статья. Табигатьтән файдалану лимитлары

1. Табигатьтән файдалану лимитлары территорияләр буенча экологик чикләүләр системасы була һәм мәгълүм бер чорга табигатьтән файдаланучы предприятиеләр өчен табигый байлыклардан файдалануның (аларны чыгаруның), әйләнә-тирә табигать мохитенә пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауның һәм агызып чыгаруның, житештерү калдыкларын барлыкка китерүнең һәм урнаштыруның иң чик күләмнәрен билгеләүдән гыйбарәт.

2. Табигатьтән файдалану лимитларын, табигый байлыклардан файдалануның (аларны чыгаруның) норматив күләмнәренә, әйләнә-тирә табигать мохитенә пычраткыч матдәләрне чыгарып ташлауның һәм агызып чыгаруның иң чик мөмкин норматив күләмнәренә, житештерү калдыкларын барлыкка китерүнең һәм урнаштыруның норматив күләмнәренә этаплап ирешүнең зарурлыгыннан чыгып, республикадагы экологик вәгъгыятьне исәпкә алып, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан билгеләнә.

3. Табигатьтән файдалануның норматив күләмнәренә ирешү чоры һәм һәр ел өчен лимитлар дәүләт һәм җирле экологик программаларында расланган күрсәткечләр нигезендә билгеләнә.

19 статья. Табигатьтән файдалануның түләүле булуы

1. Табигатьтән түләүле файдалану табигый байлыклардан файдаланган өчен түләүләрдән, табигый байлыкларны яңадан торгызу һәм саклау өчен түләүләрдән гыйбарәт.

2. Табигый байлыклардан (җир, җир асты байлыклары, су,

һава, урман һәм үзгә үсемлекләр, хайваннар дөньясы, ял итү һәм башка табигый байлыклар) файдаланган өчен түләүләр түбәндәгеләр өчен алына:

- билгеләнгән лимит чикләрендә табигый байлыклардан файдаланган өчен;

- табигый байлыклардан лимиттан тыш файдаланган өчен.

20 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитен пычраткан өчен түләүләр

1. Әйләнә-тирә табигать мохитенә пычраткыч матдәләр чыгарып ташлаган һәм агызып чыгарган өчен, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләүләр әйләнә-тирә табигать мохитенә китерелгән зыянны өлешчә компенсацияләү рәвеше була.

2. Әйләнә-тирә табигать мохитен пычраткан өчен түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- билгеләнгән нормативлар һәм лимитлар чикләрендә әйләнә-тирә табигать мохитенә пычраткыч матдәләр чыгарып ташлаган һәм агызып чыгарган өчен, калдыклар урнаштырган өчен түләүләр;

- билгеләнгән лимиттан тыш әйләнә-тирә табигать мохитенә пычраткыч матдәләр чыгарып ташлаган һәм агызып чыгарган өчен, калдыклар урнаштырган һәм аларны санкциясез җыеп туплаган һәм күмгән өчен түләүләр;

- әйләнә-тирә табигать мохитенә һәлакәтләр аркасында пычраткыч матдәләр чыгарып ташлаган һәм агызып чыгарган өчен түләүләр.

3. Пычраткыч матдәләрне чыгарып ташлаган һәм агызып чыгарган өчен, җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китергән һәм урнаштырган өчен түләүләр законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Әйләнә-тирә табигать мохитен пычраткан өчен түләүләр предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы Экология фонды счетына кертеләләр һәм Татарстан Республикасы Экология фонды тәкъдиме буенча, милек рәвешләренә, нинди ведомствога буйсынуларына карамастан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан алыналар һәм аның счетына кертеләләр.

124



21 статья. Табигый байлыкларны саклау һәм яңадан торгызу өчен, әйләнә-тирә табигать мохитенә пычраткыч матдәләр чыгарып ташлаган һәм агызып чыгарган өчен, житештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләүләр

1. Табигый байлыкларны саклау һәм яңадан торгызу өчен түләүләр бюджет ассигнованиеләрен һәм әлеге эшчәнлекне башкаруга киткән чыгымнарны кире кайтаруның компенсацион рәвеше була һәм түләүләрнең ставкаларын, башка нормативларын билгеләү юлы белән алына.

2. Табигый байлыкларны саклау һәм яңадан торгызу өчен түләүләрнең нормативларын (ставкаларын), шулай ук пычраткыч матдәләр чыгарып ташлаган һәм агызып чыгарган өчен, житештерү һәм куллану калдыкларын бәрлыкка китергән һәм урнаштырган өчен түләү нормативларын исәплап чыгару һәм куллану тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгели.

3. Түләү нормативлары, җирле шартларны, чыгарып ташланучы зарарлы матдәләрнең составын һәм үзлекләрен, табигать комплексларының үзенчәлекләрен исәпкә алып, уртак ысулият нигезендә билгеләнә.

22 статья. Татарстан Республикасының Экология фонды

1. Табигатьне саклау мәсьәләләрен хәл итүне, әйләнә-тирә табигать мохитендәге югалтуларны торгызуны, китерелгән зыянны компенсацияләүне, максатчыл экологик программаларны, проектларны һәм гамәлләрне финанслауны Татарстан Республикасының Экология фонды тормышка ашыра.

2. Фонд юридик зат була һәм коммерциягә карамаган оешма буларак төзелә.

3. Фонд акчалары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләр исәбеннән төзелә:

- әйләнә-тирә табигать мохитен пычраткан өчен түләүләр;
- табигый байлыкларны торгызу өчен түләүләр;
- табигый байлыкларга китерелгән зыянны түләттерү турындагы дәгъвалар буенча компенсация түләүләре;

- экологик хокук бозулар өчен табигатьтән файдаланучылардан алына торган штрафлар;

- законнарга һәм фондның төп бурычларына каршы килми торган башка акча чыганаклары.

4. Фонд акчалары Татарстан Республикасының Экология фондына күчерелә һәм түбәндәге тәртиптә бүленә:

- сиксән проценты - җирле (шәһәр, республика буйсынуындагы шәһәр, район) әһәмияткә ия табигатьне саклау гамәлләренә;

- егерме проценты - республика әһәмиятенә ия табигатьне саклау гамәлләренә.

5. Фонд эшләрне түләүсез һәм кайтарып бирелә торган нигезләрдә финансларга хаклы.

<u>23 статья.</u> Табигатьтән нәтиҗәле файдалануны һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклауны икътисадый хуплау

1. Татарстан Республикасында табигатьтән нәтиҗәле файдалану һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау законнар нигезендә түбәндәгечә хуплана:

- аз калдыклы һәм калдыксыз җитештерү технологияләрен керткәндә, икенчел чималларны кулланганда, табигатьне саклауны тәэмин итәрлек башка эшчәнлекне гамәлгә ашырганда, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга законнар нигезендә бирелүче салым ташламалары һәм башка ташламалар билгеләү;

- табигатьне саклау гамәлләрен башкару өчен предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга һәм гражданнарга шартнамә буенча экология фондларының бер өлешен тапшыру;

- экологик зарарлы продукция чыгарган өчен, шулай ук экологик хәвефле технологияләр кулланып чыгарылган продукция өчен махсус салымнар кертү;

- икътисадый хуплауның башка төрләрен кертү.

<u>24 статья.</u> Экологик иминләштерү

1. Экологик иминләштерү физик һәм юридик затларның милек объектларына техноген һәлакәтләр аркасында яисә предприятие-

ләрнең (оешмаларның) калдыклар чыгарып ташлап (агызып) һәм аларны урнаштырып әйләнә-тирә табигать мохитен нормадан тыш пычратулары аркасында килеп чыга торган тискәре нәтиҗәләрне бетерүгә бәйле алдан күзалланмаган чыгымнарны каплау очрагына керемнәрен аларның үзләре тарафыннан ирекле рәвештә, шулай ук юридик затларның,башка затлар гомеренә, сәламәтлегенә яисә мөлкәтенә зыян китергәндә, гражданлык җаваплылыгына әзер булуларын мәҗбүри экологик иминләштерү рәвешендә башкарыла.

2. Мәҗбүри экологик иминләштерү тәртибе һәм шартлары закон белән билгеләнә.

## V б ү л е к

## Әйләнә-тирә табигать мохитенең сыйфатын нормалаштыру

### 25 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитенең сыйфатын нормалаштыруга карата төп таләпләр

1. Әйләнә-тирә табигать мохитенең сыйфатын нормалаштыру әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынтының халыкның экологик иминлеген һәм генетик фондның сакланышын гарантияләүче, хуҗалык эшчәнлегенең тотрыклы үсеше шартларында табигый байлыклардан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны яңадан торгызуны тәэмин итүче иң чик мөмкин нормаларын билгеләү йөзеннән башкарыла.

2. Әйләнә-тирә табигать мохите сыйфатының норматив таләпләрен бозган очракта (пычраткыч матдәләрне чыгарып ташлау һәм агызу, калдыкларны барлыкка китерү һәм урнаштыру яисә әйләнә-тирә табигать мохитенә башка тискәре йогынтылар) Татарстан Республикасының Әйләнә тирә табигать мохитен һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы яисә әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары карары нигезендә предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның, участокларның, цехларның,корылмаларның, җайланмаларның эшчәнлеген законнар нигезендә туктатып торуы турындагы мәсьәләне карау өчен судка материаллар җибәрелергә мөмкин.

26 статья. Зарарлы матдәләрне чыгарып ташлауларның һәм агызып чыгаруларның нормативлары

1. Зарарлы матдәләрне, шулай ук зарарлы микроорганизмнарны һәм атмосфера һавасын, суны, туфракны пычратучы башка биологик матдәләрне чыгарып ташлауларның һәм агызып чыгаруларның иң чик мөмкин нормативлары объектның житештерү куәтләрен, чыгарып ташланучы токсикантларның массасын, әйләнә-тирә табигать мохитендә зарарлы матдәләр концентрацияләренең иң чик мөмкин нормативлары нигезендә һәр пычратучы чыганак буенча зарарлы матдәләрне чыгарып ташлауларның һәм агызып чыгаруларның тискәре нәтиҗәләре булуы турындагы мәгълүматларны һәм экосистемаларның киләчәк мөмкинлекләрен исәпкә алып билгеләнә.

2. Чыгарып ташлауларның һәм агызып чыгаруларның иң чик мөмкин нормативлары Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты тарафыннан раслана.

3. Әйләнә-тирә табигать мохите сыйфатының билгеләнгән нормативларын арттыру, аларны вакытлы нормаларга алмаштыру рөхсәт ителми.

27 статья. Тавыш, вибрация, магнит кырлары һәм башка зарарлы физик йогынтылар кимәленең иң чик мөмкин нормативлары

Тавыш, вибрация, магнит кырлары һәм башка зарарлы физик йогынтылар кимәленең иң чик мөмкин нормативлары кешеләрнең сәламәтлеген һәм хезмәткә сәләтләрен саклауны, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын, тереклек өчен уңайлы әйләнә-тирә табигать мохитен саклауны тәэмин итәрлек дәрәҗәдә билгеләнә һәм, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары белән килештереп, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты тарафыннан раслана.

28 статья. Радиация йогынтысы кимәленең иң чик мөмкин нормативлары

Әйләнә-тирә табигать мохитендә һәм азык-төлек продуктларында радиоактив матдәләрнең хәвефсез тупланышы кимәленең иң чик мөмкин нормативлары һәм кешеләргә радиация нурланышы кимәленең иң чик мөмкин нормативлары кешеләр сәламәтлегә һәм генетик фонд өчен куркыныч янамаслык аурлыкларда билгеләнә. Күрсәтелгән нормаларны әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары раслый.

29 статья. Агрохимикатларны кулланунын иң чик мөмкин нормалары

1. Минераль ашламаларны куллануның, үсемлекләрне яклау чараларын, үсеш стимуляторларын һәм башка химикатларны куллануның иң чик мөмкин нормалары туфракта һәм азык-төлек продуктларында калучы химик матдәләр микъдарының иң чик мөмкин нормативларын үтәүне, кешеләр сәламәтлеген, генетик фондны, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын саклауны тәэмин итәрлек дозаларда билгеләнә.

2. Күрсәтелгән нормативларны әйләнә-тирә мохитне саклау буенча Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары раслый.

30 статья. Азык-төлек продуктларында калучы химик матдәләр микъдарының иң чик мөмкин нормативлары

1. Азык-төлек продуктларында калучы химик матдәләр микъдарының иң чик мөмкин нормативлары кулланылучы һәр химик матдә буенча һәм аларның бергәләп тәэсир итүе буенча кеше сәламәтлеге өчен зарарсыз дип саналган иң минималь дозаны билгеләү юлы белән ачыклана.

2. Күрсәтелгән нормативларны, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары раслый.

31 статья. Продукциягә карата экологик таләпләр

1. Яңа техника, технологияләр, материаллар, матдәләр стандартларына һәм житештерү, саклау, транспортлау һәм куллану чорында әйләнә-тирә табигать мохитенә һәм кешеләр сәламәтлегенә зарарлы йогынты ясарлык башка продукция стандартларында әйләнә-тирә мохиткә йогынтының иң чик мөмкин нормативларын үтәүне тәэмин итәрлек экологик таләпләр билгеләнә.

2. Житештерү һәм куллану продукциясенә карата экологик таләпләр продукцияне житештерү, саклау, транспортлау һәм куллану чорында әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынтының иң чик мөмкин нормативларын үтәүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Күрсәтелгән таләпләр һәм аларны нигезләү ысуллары санитария-эпидемиология күзәтүе органнары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә раслана.

32 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитенең иң чик мөмкин йөкләнешләр

1. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары сәнәгать, авыл хужалыгы, урман хужалыгы үсешенең һәм шәһәрләрне, башка торак пунктларын төзү һәм үзгәртеп коруның территория-житештерү комплексларын оештырганда, әйләнә-тирә табигать мохитенең киләчәк мөмкинлекләреннән, территория һәм табигый байлыклардан нәтиҗәле файдалануның зарурлыгыннан чыгып, халыкның яшәеше өчен иң уңайлы шартларны тәэмин итү, табигый экологик системаларның җимерелүен һәм әйләнә-тирә табигать мохитендә кайтарып алалмаслык үзгәрешләр булдырмау йөзеннән, дәүләт экология экспертизасы нигезендә әйләнә-тирә табигать мохитенең иң чик мөмкин йөкләнеш нормалары билгеләнә.

33 статья. Санитар һәм саклау зоналарының нормативлары

Санитар һәм саклау зоналарының нормативлары, сулыкларны, су белән тәэмин итүче башка чыганакларны, курортларны һәм дәвалау-сәламәтләндерү зоналарын, торак пунктларын һәм башка

территорияләрне пычранудан һәм бүтән зарарлы йогынтылардан һәм экология экспертизасы объектын кулланунын башка зарарлы йогынтыларыннан саклау йөзеннән, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан билгеләнә.

Әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы матдәләр бүлеп чыгару чыганаклары булган технологик процессолы предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар өчен санитар саклау зоналары төзү карала.

## VI бүлек

## Дәүләт экология экспертизасы

<u>34 статья.</u> Дәүләт экология экспертизасының максатлары һәм принциплары

1. Дәүләт экология экспертизасы хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төр эшчәнлекнең экологик таләпләргә туры килү-килмәвен билгеле һәм, бу эшчәнлекнең әйләнә-тирә табигать мохитенә мөмкин булган тискәре йогынтысын, алар белән бәйле башка социаль, икътисадый һәм экология экспертизасы объектын кулланунын бүтән йогынтыларын киметү йөзеннән үткәрелә.

Дәүләт экология экспертизасы мәҗбүрилек, объективлык һәм бәйсезлек, аның нәтиҗәләренең фәнни нигезләнгәнлеге һәм законлылыгы, ведомстволарга буйсынмаучанлык, киң хәбәрдарлык принципларында гамәлгә ашырыла.

2. Проектлар һәм программалар буенча эшләрне финанслау һәм гамәлгә ашыру дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе булганда гына башкарыла.

3. Экология эспертизасы үткәрү тәртибе законнар белән җайга салына.

<u>35 статья.</u> Дәүләт экология экспертизасының объектлары. Экологик паспортлаштыру

1. Дәүләт экология экспертизасын үтәргә тиешле объектлар закон белән билгеләнә.

2. Файдаланганда әйләнә-тирә табигать мохитенә тискәре йогынты ясый торган барлык объектларның экологик паспортлары булырга тиеш.

3. Экологик паспортлаштыру Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланган кагыйдәләр нигезендә алып барыла.

36 статья. Дәүләт экология экспертизасының таләпләрен үтәмәгән өчен җаваплылык һәм экспертларның җаваплылыгы

1. Дәүләт экология экспертизасы бәяләмәләренең таләпләрен үтәмәгән өчен предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләре, шулай ук гражданнар законнар нигезендә җаваплы булалар.

2. Эксперт комиссияләренең рәисе һәм әгъзалары үз бәяләмәләренең дөреслеге һәм нигезлелеге өчен законнар нигезендә җаваплы булалар. Эксперт комиссиясенең карарына карата судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

37 статья. Иҗтимагый экологик экспертиза

1. Фәнни коллективлар һәм җәмәгать оешмалары тарафыннан үз инициативалары буенча үткәрелүче иҗтимагый экологик экспертиза нәтиҗәләре дәүләт экология экспертизасының тиешле органнары тарафыннан каралу мәҗбүри.

2. Экспертларның иҗтимагый берләшмәләре рәисе һәм әгъзалары үз бәяләмәләренең дөреслеге һәм нигезлелеге өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

132



## VII б ү л е к

### Предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны урнаштырганда, проектлаштырганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм файдалануга тапшырганда куелучы экологик таләпләр

**38 статья.** Предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны урнаштырганда, проектлаштырганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм файдалануга тапшырганда куелучы гомуми экологик таләпләр

1. Табигать мохитенең торышына турыдан-туры йә башкача йогынты ясаучы хуҗалык эшчәнлеге объектларын урнаштырганда, проектның техник-икътисадый нигезләгәндә, проектлаштырганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм файдалануга тапшырганда, экологик иминлек һәм кешеләрнең сәламәтлеген саклау таләпләре үтәлергә, табигатьне саклау, табигый байлыклардан нәтиҗәле файдалану һәм аларны ишәйтү, әйләнә-тирә табигать мохитен сәвыктыру гамәлләре күз алдында тотылырга тиеш.

2. Күрсәтелгән таләпләр бозылганда, юридик һәм физик затларның хокукка каршы эшчәнлеге законнар нигезендә туктатып торыла яисә бөтенләй туктатыла.

3. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнарының һәм Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтү буенча дәүләт комитетының уңай бәяләмәсе, дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнарының, җирле үзидарә органнарының карарлары булганда гына предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны төзү урыннары билгеләнә. Халыкның экологик мәнфәгатьләренә кагылучы объектларны урнаштырганда карар халык фикерен яисә референдум нәтиҗәләрен исәпкә алып кабул ителә.

39 статья. Предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны техник-икътисадый нигезләүгә һәм проектлаштыруга карата экологик таләпләр

1. Проектны техник-икътисадый нигезләгәндә, предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны проектлаштырганда әйләнә-тирә мохит халәте, бүгенге фәнни-техник алгарыш дәрәҗәсе һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә иң чик мөмкин йөкләнешләр исәпкә алынырга, җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерүне һәм урнаштыруны булдырмый калуның, әйләнә-тирә табигать мохитен пычранулардан саклауның ышанычлы һәм нәтиҗәле чаралары, зарарлы калдыкларны зарарсызландыру һәм файдалы эшкә тоту, табигый байлыкларны сак кулланучы, аз калдыклы һәм калдыксыз эшләүче технологияләрне һәм җитештерүләрне гамәлгә ашыру, табигый байлыклардан нәтиҗәле файдалану һәм аларны яңадан торгызу, әйләнә-тирә табигать мохитен савыктыру күз алдында тотылырга тиеш.

2. Дәүләт экология экспертизасы үтмәгән проектларны техник-икътисадый нигезләү һәм предприятиеләр, башка объектлар төзү турындагы мондый проектлар расланмаска тиеш. Аларны гамәлгә ашыру эшләрен финанслау тыела.

40 статья. Предприятиеләр, корылмалар һәм башка объектлар төзүгә, үзгәртеп коруга куелучы экологик таләпләр

1. Предприятиеләр, корылмалар һәм башка объектлар төзү һәм үзгәртеп кору расланган проектлар буенча һәм табигатьне саклау, санитария, шулай ук төзелешнең гамәлдәге нормаларын һәм кагыйдәләрен катгый рәвештә үтәгән килеш кенә башкарыла. Расланган проектны яисә проект эшләренең хакын экологик иминлек таләпләренә зыян китерерлек итеп үзгәртү тыела.

2. Төзелеш эшләрен алып барганда әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, табигый байлыклардан нәтиҗәле файдалану, җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу, территорияләрне төзекләндерү һәм әйләнә-тирә табигать мохитен савыктыру чаралары күрелә.

3. Әлеге законда бәян ителгән таләпләр бозылганда, төзелеш эшләре, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Та-

тарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты күрсәтмәсе нигезендә, билгеләнгән җитешсезлекләр бетерелгәнче, туктатып торыла.

41 статья. Предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны файдалануга тапшырганда куелучы экологик таләпләр

1. Проектта каралган экологик таләпләр тулысынча үтәлсә генә, Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле башка дәүләт органнары, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе дәүләт комитеты вәкилләре катнашында төзелүче кабул итү комиссияләре актлары буенча гына предприятиеләр, корылмалар һәм башка объектлар файдалануга тапшырылырга тиеш.

2. Табигый байлыкларны сак кулланучы, аз калдыклы һәм калдыксыз эшләүче заманча технологияләр белән, зарарлы калдыкларны зарарсызландыру һәм файдалы эшкә тоту, пычраткыч матдәләрне агызып чыгару һәм чыгарып ташлауның мөмкин нормативларын урнаштыру корылмалары һәм җайланмалары белән, әйләнә-тирә табигать мохитен пычратуны тикшереп тору җайланмалары белән тәэмин ителмәгән объектларны, табигатьне саклау, туфракның уңдырышлылыгын торгызу, әйләнә-тирә табигать мохитен сәвыктыру буенча проектланган эшләр төгәлләнмәгән объектларны файдалануга тапшыру тыела.

3. Кабул итү комиссияләренең рәисе һәм әгъзалары объектларны кабул итү тәртибен бозган өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

## VIII бүлек. Предприятиеләрдән, корылмалардан, башка объектлардан файдаланганда һәм башка эшчәнлекне башкарганда куелучы экологик таләпләр

### 42 статья. Предприятиеләрдән, корылмалардан һәм башка объектлардан файдаланганда куелучы гомуми экологик таләпләр

1. Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, гражданнар әйләнә-тирә табигать мохите сыйфатының расланган технологияләр нигезендә билгеләнгән нормативлары таләпләрен үтәргә, экологик яктан хәвефсез технологияләрне һәм җитештерүләрне гамәлгә кертү, чистарту корылмаларының, технологик җиһазларның, җайланмаларның һәм калдыкларны тикшереп тору, зарарсызландыру һәм файдалы эшкә тоту чараларының ышанычлы һәм нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү таләпләрен үтәргә, җирләрне, җир асты байлыкларын, суларны, урманнарны һәм башка үсемлекләр, хайваннар дөньясын саклау буенча гамәлләр уздыру, табигый байлыклардан нәтиҗәле файдалану һәм аларны яңадан җитештерү таләпләрен үтәргә тиешләр.

2. Расланган нормативлар һәм лимитлар чикләрендә зарарлы матдәләрне чыгарып ташлау һәм агызып чыгару, калдыкларны урнаштыру Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә табигать мохитен һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы тарафыннан бирелүче рөхсәт нигезендә башкарыла. Рөхсәт кәгазендә зарарлы матдәләрне чыгарып ташлауның һәм агызып чыгаруның иң чик мөмкин нормативлары, калдыкларны кабат эшкәртү, файдалы эшкә тоту шартлары һәм әйләнә-тирә табигать мохитен, кешеләр сәламәтлеген саклауны тәэмин итүче башка шартлар билгеләнә.

3. Зарарлы матдәләрне чыгарып ташлауның һәм агызуның, барлыкка китерүнең һәм күмүнең билгеләнгән нормативларын, зарарлы матдәләрне чыгарып ташлауга, агызуга, күмүгә рөхсәттә каралган әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча башка шартларны һәм таләпләрне үтәмәгәндә, шулай ук кеше сәламәтлегенә зыян килү куркынычы тудырылганда, зарарлы матдәләрне чыгарып ташлау, агызу, күмү һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә һәм кеше сәламәтлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республи-

касының махсус вәкаләтле дәүләт органнарының күрсәтмәсе буенча туктатып торылырга һәм суд карары нигезендә предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның эшчәнлеге дә туктатып торылырга мөмкин.

4. Экологик яктан зарарлы объектларның эшчәнлеген үзгәртү Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле башка дәүләт органнары белән килешеп башкарыла.

43 статья. Авыл хуҗалыгында куелучы экологик таләпләр

1. Авыл хуҗалыгын алып баручы предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, аларның урындагы затлары һәм гражданнар туфракны, урманнарны һәм башка үсемлекләр, хайваннар дөньясын табигать афәтләренең зарарлы йогынтысыннан, катлаулы авыл хуҗалыгы техникасы, химик матдәләр куллануның, мелиорация эшләренең һәм әйләнә-тирә табигать мохитенең торышын начарайтучы, кешеләр сәламәтлегенә зыян китерүче башка факторларның тискәре йогынтысыннан саклау буенча чаралар комплексын үтәргә тиешләр.

2. Терлекчелек фермаларының һәм комплексларының, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүче предприятиеләрнең туфракны, җир өсте һәм җир асты суларын, җир өстендә җыелган суларны һәм атмосфера һавасын пычранудан саклаучы кирәкле санитар-саклау зоналары һәм чистарткыч корылмалары булырга тиеш. Күрсәтелгән таләпләр үтәлмәгәндә, әйләнә-тирә табигать мохитенә һәм кешеләр сәламәтлегенә зыян китерелгәндә, законнарда билгеләнгән тәртиптә авыл хуҗалыгы объектларының һәм башка объектларның экологик зарарлы эшчәнлеге туктатып торыла яисә бөтенләй туктатыла.

44 статья. Мелиорация эшләрен планлаштырганда, проектлаштырганда, үтәгәндә куелучы экологик таләпләр

1. Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, аларның урындагы затлары һәм гражданнар мелиорация эшләрен планлаштырган-

да, проектлаштырганда, башкарганда һәм мелиорация системаларыннан файдаланганда су балансын үтәү, җирләрдән нәтиҗәле файдалану, суны сакчыл сарыф итү буенча, җирләрне, урманнарны һәм башка үсемлекләр дөньясын ярлылanудан, су басудан, су астында калудан, тозланудан саклау буенча һәм әйләнә-тирә табигать мохите өчен башка зарарлы йогынтыларны киметү буенча кирәкле барлык гамәлләрне үтәргә тиешләр.

2. Күрсәтелгән таләпләр бозылганда, кимчелекләрне бетергәнчегә кадәр, әлеге системаларны проектлаштыру, төзү яисә алардан файдалану законда билгеләнгән тәртиптә туктатып торыла йә бу эшләр бөтенләй туктатыла.

<u>45 статья.</u> Энергетика объектларына куелучы экологик таләпләр

1. Энергетика предприятиеләрен, җайланмаларын һәм башка объектларын урнаштыру, проектлаштыру, төзү һәм алардан файдалану әлеге Законның 38-42 статьялары таләпләре нигезендә башкарыла.

2. Су электростанцияләрен урнаштырганда, проектлаштырганда, төзегәндә шушы төбәкнең электр энергиясенә булган хакыйкый ихтыяҗлары, объектны урнаштыру җирлегенең рельефы тулысынча исәпкә алынырга, җирләрне һәм урманнарны, торак пунктларын, табигать, тарих, мәдәният ядкярләрен югары дәрәҗәдә саклау, балык запасларын нәтиҗәле саклау чаралары, сусаклагыч юлын чистартканда йә су басканда агачларны вакытында файдалы эшкә тоту һәм туфракның уңдырышлы катламын саклау, әйләнә-тирә табигать мохитенә тискәре йогынтыларны булдырмый калу чаралары күрелергә тиеш.

3. Җылылык электростанцияләрен проектлаштырганда һәм төзегәндә, аларны югары нәтиҗә бирә торган фильтрлар һәм зарарлы калдыклардан, чыгарып ташланган һәм агызып чыгарылган зарарлы матдәләрдән чистарта торган башка чаралар белән тәэмин итүне, ягулыкның экологик имин төрләрен куллануны, су белән тәэмин итүнең ябык системасын кертүне, зарарлы матдәләрне чыгарып ташлауны һәм агызып чыгаруны автомат тикшерү чаралары белән тәэмин итүне күздә тотарга кирәк.

4. Атом энергетикасы объектларын проектлаштырганда, ур-

наштырганда, төзегәндә, файдалануга тапшырганда һәм алардан файдаланганда халыкара кагыйдәләр нигезендә әйләнә-тирә табигать мохитенең һәм халыкның радиация иминлеген тулысынча тәэмин итү буенча чаралар күрелә. Халык тыгыз урнашкан территорияләрдә, курорт, ял итү, дәвалау-сәламәтләндерү зоналары территорияләрендә, санитария ягыннан саклана торган тирәлекләрдә, сейсмик куркыныч зоналарда һәм республика күләмендә әһәмиятле зур сулыклар тирәсендә атом энергетикасы объектларын урнаштыру, проектлаштыру, төзү тыела.

5. Күрсәтелгән таләпләр бозылганда, энергетика объектларын проектлаштыру, төзү һәм аларның эшләве, билгеләнгән җитешсезлекләр бетерелгәнчегә кадәр, законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатып торыла яисә бөтенләй туктатыла.

46 статья. Шәһәрләрне һәм башка торак пунктларын проектлаштырганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда, төзекләндергәндә һәм яшелләндергәндә куелучы экологик таләпләр

1. Шәһәрләрне һәм башка торак пунктларын проектлаштыру, төзү, үзгәртеп кору, төзекләндерү һәм яшелләндерү халыкның тормышы һәм сәламәтлеге өчен уңай әйләнә-тирә табигать мохите тудырырга тиеш. Сәнәгать һәм башка хуҗалык объектлары халыкның сәламәтлеге һәм гомере өчен, санитария-көнкүреш шартлары өчен зарарлы факторларның тискәре йогынтысы булмаслык итеп урнаштырылырга тиеш.

2. Шәһәрләрне һәм башка торак пунктларын планлаштырганда һәм төзегәндә, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча гамәлләр күздә тотылырга тиеш.

3. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау максатларында, зур шәһәрләр һәм сәнәгать үзәкләре, экологик яктан хәвефле эре объектлар тирәсендә, хуҗалыкта интенсив файдаланыла торган зоналардан алынып, урман-парклар, яшел саклау зоналары төзелә, бу урыннарда табигатьтән файдалану чикләнә.

4. Шактый зур мәйданнарны биләүче шәһәрләр, юллар һәм башка объектлар проектлаштырганда һәм төзегәндә "яшел" кори-

дорлар һәм кыргый хайваннарның күченеп килүен һәм тоткарлыксыз үтеп керүләрен тәэмин итүче махсус корылмалар куелган тотылырга тиеш.

47 статья. Атом-төш материалларыннан, радиоактив матдәләрдән һәм башка ионлы нурланыш чыганакларыннан файдаланганда куелучы экологик таләпләр

1. Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, аларның урындагы затлары һәм гражданнар атом-төш материалларын, радиоактив матдәләрне, ионлы нурланышның башка чыганакларын җитештерү, саклау, ташу, куллану, файдалы эшкә тоту, аларны әерып алу һәм күму кагыйдәләрен үтәргә тиеш, радиация нормаларының кешеләр сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерерлек дәрәҗәдә артуы турында кичекмәстән Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитетына хәбәр итәргә, радиацияне киметү һәм радиация белән агулану чыганакларын бетерү чараларын күрергә тиешләр.

2. Радиоактив калдыкларны күму өчен рөхсәтләр Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты тарафыннан бирелә.

3. Ионлы нурланыш чыганаклары белән эш итү кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итмәгән, лицензия шартларын бозган предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә табигать мохитен һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты күрсәтмәсе буенча законнар нигезендә ионлы нурланыш чыганакларыннан файдалану эшчәнлегенә хокуктан мәхрүм ителергә мөмкин.

48 статья. Химик матдәләрне кулланганда куелучы экологик таләпләр

1. Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, аларның урын-

дагы затлары һәм гражданнар авыл һәм урман хуҗалыгында үсемлекләрне саклау, аларның үсешен тизләтү чаралары, минераль ашламалар буларак кулланылучы һәм сәнәгатьнең башка тармакларында кулланылучы химик матдәләрне җитештерү, саклау, ташу һәм куллану кагыйдәләрен, аларны куллануның билгеләнгән нормативларын үтәргә һәм кулланганда аларның кешеләр сәламәтлегенә, әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы йогынтысын булдырмау чараларын күрергә тиешләр.

2. Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары белән берлектә авыл хуҗалыгында куллану өчен рөхсәт ителгән химик препаратларның исемлеген һәм азык-төлек продуктларында кала торган химик матдәләрнең иң чик мөмкин нормаларын даими рәвештә раслап тора.

3. Кешеләр сәламәтлегенә турыдан-туры яисә башкача тәэсир итәрлек йә үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларына тискәре йогынты ясарлык яңа химик матдәләрне бары тик Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты рөхсәте белән генә кулланырга мөмкин. Таркалмый торган һәм кешеләр организмына, әйләнә-тирә табигать мохитенә актив йогынты ясый торган агулы химик препаратларны куллану тыела. Сәнәгатьтә һәм башка хуҗалык объектларында кулланылучы химик матдәләрнең экологик зарарлы йогынтысыннан әйләнә-тирә табигать мохитен, кешеләр сәламәтлеген кайгырту максатларында, саклау кагыйдәләре Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты тарафыннан раслана.

4. Әлеге кагыйдәләрне, әйләнә-тирә табигать мохитен химик матдәләр белән пычратып, кешеләр сәламәтлегенә, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына куркыныч тудырырлык итеп бозганда, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы карары белән тиешле химик препаратларны җитештерү, саклау, ташу, куллану тыела.

**49 статья.** Әйләнә-тирә табигать мохитен зарарлы биологик йогынтыдан саклау

1. Әйләнә-тирә табигать мохитенә тискәре йогынты ясый торган предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны, технологияләрне урнаштырганда, проектлаштырганда, төзегәндә, файдалануга тапшырганда һәм алардан файдаланганда табигать мохитендәге микробларның, гөмбәчекләрнең, вирусларның һәм башка төрле микроорганизмнарның, биологик матдәләрнең иң чик мөмкин концентрациясенең Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган нормативлары саклануырга тиеш.

2. Әйләнә-тирә табигать мохитенә биологик йогынты ясарлык предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар яисә гражданнар микроорганизмнарны һәм биологик матдәләрне экологик яктан зарарсыз җитештерүне, саклауны, ташуны һәм зарып алуны тәэмин итәргә, бәла-казаларны һәм һәлакәтләрне булдырмау, әйләнә-тирә табигать мохитенә, кешеләр сәламәтлегенә һәм генетик фондына биологик йогынтылар аркасында зарар китермәү һәм зарар китерелгәндә, аларны бетерү буенча чаралар күрергә һәм аларны тормышка ашырырга тиеш.

3. Тиешле төбәк табигатенә хас булмаган, шулай ук ясалма юл белән табылган биологик объектларның исәпсез артуын булдырмый торган нәтиҗәле чаралар күрмичә, аларны куллану һәм арттыру тыела.

4. Әйләнә-тирә табигать мохитенә ясалган биологик йогынтының чыганакларын күзәтеп торуны, исәпкә алуны һәм биологик йогынты дәрәҗәсен тикшереп торуны Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты һәм шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары башкара.

5. Әйләнә-тирә табигать мохитенә биологик йогынтыларның иң чик мөмкин күләмнәренең билгеләнгән нормативларын арттырганда, микроорганизмнарны һәм матдәләрне биологик җитештерү, саклау, куллану тәртибен бозганда, әлеге пычрату чыганаклары булган предприятиеләрнең, башка объектларның эше законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатып торыла яисә бөтенләй туктатыла.

50 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитен тавыштан, вибрациядән, электромагнит кырларыннан һәм башка зарарлы физик йогынтылардан саклау

1. Дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, гражданнар җитештерү, җәмәгать һәм торак биналарында, урамнарда, ишек алларында, шәһәр һәм башка торак пунктлары мәйданнарында, шәһәр яны ял итү зоналарында, кыргый хайваннарның һәм кошларның күпләп туплану һәм үрчү урыннарында әйләнә-тирә табигать мохитенә җитештерүдәге көчле тавышларның, вибрациянең, электр магниты кырларының зарарлы йогынтысын һәм башка физик йогынтыларны булдырмау һәм аларны бетерү буенча кирәкле чаралар күрергә тиешләр.

2. Җитештерүдәге һәм транспорттагы көчле тавышларның, вибрациянең, электр магниты кырларының кеше сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынтысының, башка физик йогынтыларның иң чик мөмкин кимәлләре нормативларын арттыру тыела. Шәһәрләрне һәм башка торак пунктларын планлаштырганда һәм төзегәндә, предприятиеләрне, цехларны, технологик линияләрне проектлаштырганда, төзегәндә һәм үзгәртеп корганда, яңа техника төзегәндә һәм үзләштергәндә, җир, су һәм һава юлы транспортын үзгәртеп корганда һәм проектлаштырганда, алардан файдаланганда, күрсәтелгән нормативларны үтәүне гарантияләүче чаралар күрелә.

3. Күрсәтелгән нормативлар бозылганда, предприятиеләрнең, цехларның, агрегатларның һәм башка җайланмаларның эшләве, зарарлы йогынты ясаучы транспорт чараларыннан, тавыш, вибрация, магнит кырлары чыганакларыннан һәм физик йогынты ясаучы башка төр чыганаклардан файдалану, ачыкланган кимчелекләр бетерелгәнчегә кадәр, законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатып торыла яисә бөтенләй туктатыла.

51 статья. Җитештерү, көнкүреш калдыкларыннан һәм башка калдыклардан әйләнә-тирә табигать мохитен саклау

1. Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле

үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, аларның урындагы затлары һәм гражданнар житештерү һәм көнкүреш калдыкларын зарарсызландыру, эшкәртү, файдалы эшкә тоту, туплау яисә күмү буенча нәтиҗәле чаралар күрергә, гамәлдәге экология, санитария-гигиена нормаларын һәм кагыйдәләрен, эпидемиягә каршы нормаларны һәм кагыйдәләрне үтәргә тиешләр.

2. Хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек барышында барлыкка килүче житештерү һәм куллану калдыклары паспортлаштырылырга, зарарсызландырылырга, эшкәртелергә һәм кабат файдаланылырга, тупланырга йә күмелергә тиеш.

3. Хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек нәтиҗәсендә килеп чыккан калдыкларны барлау һәм аларны аерып алу өчен предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, аларның урындагы затлары һәм гражданнар җаваплы була.

4. Калдыкларны туплау һәм күмү дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары тарафыннан билгеләнә торган урыннарда, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты белән килешеп, Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы тәкъдиме нигезендә башкарыла.

5. Калдыкларны гомуми кулланылыштагы сулыкларга, җир астындагы сулы горизонтларга ташлау тыела.

6. Үтә куркыныч һәм аеруча агулы калдыкларны күмү Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы һәм санитария-эпидемиология күзәтүе органнары рөхсәте белән генә башкарыла.

7. Шәһәр һәм башка торак пунктлары тирәләрендә һәм территорияләрендә, халык тыгыз тупланган районнарда, су, курорт, дәвалау-савыктыру һәм ял итү зоналарында һәм әйләнә-тирә табигать мохите торышының, кешеләр сәламәтлегенең начараю куркынычы туарга мөмкин булган башка урыннарда зарарлы калдыкларны күмү тыела.

8. Күрсәтелгән кагыйдәләр бозылганда, предприятиеләрнең һәм башка объектларның эшчәнлеге законнарда билгеләнгән тәртиптә чикләнә яисә бөтенләй туктатыла.

52 статья. Хәрби һәм саклану объектларына, хәрби эшчәнлеккә куелучы экологик таләпләр

Законнар тарафыннан куелучы экологик таләпләр хәрби һәм саклану объектларына да, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырылучы хәрби эшчәнлеккә дә, гаскәрләрнең һәм хәрби техниканың урнашуына да тулысынча кагыла.

53 статья. Урман һәм урман сәнәгате хуҗалыгына куелучы экологик таләпләр

Урман һәм урман сәнәгате хуҗалыгын алып баручы предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, гражданнар экологик таләпләрне һәм нормативларны үтәргә, урман байлыкларын ишәйтүне һәм аларны урманнарның мохитенә һәм байлыгына каршы килми торган итеп даими кулланыны тәэмин итүче табигый урман комплексларын саклауга юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашырырга тиешләр.

54 статья. Климатны һәм Җирнең озон катламын саклау

Әйләнә-тирә табигать мохитен климаттагы һәм Җирнең озон катламындагы экологик зарарлы үзгәрешләрдән саклау озон катламын боэучы җитештерүне һәм сәнәгатьтә, көнкүрештә химик һәм башка матдәләр куллануны тыю юлы белән тәэмин ителә.

IX бүлек
Гадәттән тыш экологик вәзгыять, экологик бәла-каза һәм һәлакәт зоналары

55 статья. Гадәттән тыш экологик вәзгыять зоналары

1. Татарстан Республикасының хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек нәтиҗәсендә, табигый бәла-казаларның җимергеч йогынтысы нәтиҗәсендә әйләнә-тирә табигать мохитендә кешеләр сәламәтлегенә, табигый экологик системаларның торышына, үсемлек һәм хайваннарның генетик фондлары торышына куркыныч янаучы тотрыклы тискәре үзгәрешләр бара торган җирым территорияләре

гадәттән тыш экологик вәгыять зоналары дип игълан ителә.

2. Гадәттән тыш экологик вәгыять зонасында предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның (цехларның, агрегатларның, җайланмаларның) әлеге вәгыятьне тудыручы һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы йогынты ясаучы эшчәнлеге туктатып торыла, кешеләрне күчерү, әйләнә-тирә табигать мохитен торгызу һәм саклау буенча чаралар күрелә.

3. Гадәттән тыш экологик вәгыять зоналарын саклау гамәлләрен финанслау, беренче чиратта, министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, табигать мохитен начарайтуның, бәла-казаларның яисә һәлакәтләрнең турыдан-туры гаепле затлары исәбеннән, шулай ук Татарстан Республикасының республика бюджетындагы максатчыл акчалар исәбеннән башкарыла.

56 статья. Экологик бәла-каза һәм һәлакәт зоналары

1. Татарстан Республикасының табигый һәм антропоген үзгәрешләр нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохитендә элекке хәленә кайтарып булмаслык зур үзгәрешләр барлыкка килгән һәм шулар аркасында кешеләрнең сәламәтлеге шактый начарайган, табигый тигезлеге бозылган һәм алга таба тагын да начарая бара торган территорияләре экологик бәла-каза һәм һәлакәт зоналары дип игълан ителә.

2. Экологик бәла-каза һәм һәлакәт зоналарында, зона территориясендә яшәүче халыкка хезмәт күрсәтүләр белән бәйле объектлардан гайре, барлык хуҗалык объектларының эшчәнлеге туктатыла, яңа хуҗалык объектлары төзү, үзгәртеп кору тыела, табигатьтән һәр төрле файдалану чикләнә, табигый байлыкларны торгызу, ишәйтү һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча чаралар күрелә.

3. Экологик бәла-каза һәм һәлакәт зоналарын саклау гамәлләрен финанслау, беренче чиратта, министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, табигать мохитен начарайтуның, бәла-казаларның яисә һәлакәтләрнең турыдан-туры гаепле затлары исәбеннән, шулай ук Татарстан Республикасының республика бюджетындагы максатчыл акчалар исәбеннән, Татарстан Республикасының Экология фонды

һәм Минераль ресурслар запасын ишәйтү һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча бюджеттан тыш фонд акчалары исәбеннән башкарыла.

57 статья. Экологик бәла-каза зоналарында Татарстан Республикасы гражданнарына ташламалар һәм компенсацияләр

Экологик бәла-каза зоналарында калган һәм экологик бәла-казалар (һәлакәтләр) аркасында зыян күргән гражданнар законнар нигезендә компенсацияләр һәм ташламалар алырга хаклы.

X б ү л е к
Махсус сакланылучы табигать территорияләре
һәм объектлары

58 статья. Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды

1. Дәүләт табигать тыюлыклары, милли парклар, табигать парклары, дәүләт табигать заказниклары, табигать ядкәрләре, дендрология парклары һәм ботан бакчалары, дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлары, яшел зоналар, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләргә керүче сирәк очрый торган яисә бөтенләй бетү куркынычы янаган үсемлекләр һәм хайваннар Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фондын тәшкил итәләр һәм, бүгенге һәм киләчәк буын кешеләренең ихтыяҗларын исәпкә алып, дәүләт тарафыннан махсус саклана лар.

2. Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, шулай ук законнарда каралган очракларда, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагында булырга мөмкин.

3. Табигать-тыюлык фонды һәм аның состав өлешләрен саклау режимы законнар белән билгеләнә.

59 статья. Дәүләт табигать тыюлыклары

1. Дәүләт табигать тыюлыклары территорияләрендә махсус сакланылучы табигать комплекслары һәм табигый табигать мохите буларак табигатьне саклау, фәнни, экологик-мәдәни әһәмияткә ия булган объектлар (җир,су,җир асты байлыклары, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы), гадәти һәм сирәк ландшафтлар, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының генетик фондын саклау урыннары хуҗалык кулланылышыннан тулысынча алыналар.

2. Дәүләт табигать тыюлыклары табигый үзгәрешләрне һәм күренешләрне, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының генетик фондын, үсемлекләр һәм хайваннарның аерым төрләрен һәм берләлеклерен, гадәти һәм уникаль экологик системаларны саклау һәм өйрәнү максатларындагы табигатьне саклау буенча фәнни-тикшеренү һәм экологик-мәдәни учреждениеләр булалар.

3. Дәүләт табигать тыюлыклары законнарда билгеләнгән тәртиптә төзеләләр.

4. Дәүләт тыюлыгы территориясендә тыюлык максатларына каршы килә торган яисә әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерә торган хуҗалык эшчәнлеге, ял итү һәм башка эшчәнлек алып бару тыела. Фәнни-тикшеренү, янгынга каршы эшләр тыюлык максатларына каршы килмәскә тиеш.

5. Тыюлык режимын тәэмин итү өчен тыюлык территориясе тирәсендә саклау зоналары төзелә, анда табигать тыюлыгы комплексларына йогынты ясый торган эшчәнлек алып бару тыела.

6.Тыюлыкларны саклау режимын үтәүне тыюлыкны саклау хезмәтләре тәэмин итә. Табигать тыюлыкларының эшчәнлегенә җитәкчелек итүне һәм аны тикшереп торуны Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

60 статья. Милли парклар

1. Үз территорияләрендә (акваторияләрендә) махсус экологик, тарихи һәм зәүкый әһәмияткә ия булган һәм табигатьне саклау, мәдәни-агарту, фәнни һәм мәдәни максатлар өчен һәм җайга салынучы туризм өчен билгеләнгән милли парклар табигатьне саклау, экологик-агарту һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләре була-

лар.

2. Милли парклар законнарда билгеләнгән тәртиптә төзеләләр.

3. Милли парклар территорияләрендә булган җир, сулар, җир асты байлыклары, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы милли парклар файдалануына (карамагына) биреләләр.

4. Билгеләнгән тәртиптә дәүләт саклавына куелган тарихи-мәдәни объектлар милли парклар файдалануына бары тик тарихи һәм мәдәни хәзинәләрне саклау буенча дәүләт органнары белән килешенеп кенә тапшырыла.

5. Милли парклар тирәсендә табигатьтән чикләнгән рәвештә файдалану режимы нигезендә саклау зоналары төзелә.

61 статья. Табигать парклары

1. Үз территорияләрендә (акваторияләрендә) экологик һәм зәүкый әһәмияткә ия табигый комплекслары һәм объектлары булган һәм табигатьне саклау, агарту һәм ял итү максатлары өчен билгеләнгән табигать парклары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары карамагындагы табигатьне саклау, ял итү учреждениеләре булалар.

2. Табигать парклары законнарда билгеләнгән тәртиптә төзеләләр.

3. Табигать паркларына түбәндәге бурычлар йөкләнә:

а) табигать мохитен, табигый ландшафтларны саклау;

б) ял итү (шул исәптән массакүләм) өчен шартлар тудыру һәм ял итү ресурсларын саклау;

в) табигатьне саклауның нәтиҗәле ысулларын эшләү һәм тормышка ашыру, табигать парклары территорияләреннән ял итү өчен файдалану шартларында экологик балансны хуплау.

4. Һәр табигать паркының аерым үзенчәлекләре, аларны зоналарга бүлү һәм аларның режимы Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә табигать мохитен һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы күрсәтмәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланучы шушы парк турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

62 статья. Дәүләт табигать заказниклары

1. Табигый байлыкларның билгеле бер төрен саклау яисә торгызу өчен билгеләнгән табигать комплексы дәүләт табигать заказнигы дип игълан ителә, бер үк вакытта табигый байлыкларның башка төрләреннән файдалану да чикләнгән һәм килешенгән булырга тиеш.

2. Дәүләт табигать заказниклары законнарда билгеләнгән тәртиптә төзеләләр.

3. Заказник территориясендә хуҗалык эшчәнлеге, ял итү һәм заказникны оештыру максатларына каршы килүче яисә әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерүче башка эшчәнлек алып бару тыела.

63 статья. Табигать ядкярләре

1. Реликт һәм фәнни әһәмияткә, экология-агарту әһәмиятенә ия булган һәм дәүләт тарафыннан махсус саклануга мохтаҗ кайбер сирәк очрый торган табигый объектлар һәм табигый комплекслар табигать ядкярләре дип игълан ителә.

2. Табигый объектлар һәм комплекслар табигать ядкярләре итеп законнарда билгеләнгән тәртиптә игълан ителә.

3. Табигый объектлар һәм комплекслар булган территорияләрдә табигать ядкярenә һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерә торган яисә аның торышын һәм саклануын начарайта торган һәртөрле эшчәнлек тыела.

4. Территорияләрендә табигать ядкярләре дип игълан ителгән объектлар һәм комплекслар булган предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар аларның торышы һәм саклануы өчен тулысынча җаваплы булалар.

64 статья. Дендрологик парклар һәм ботан бакчалары

1. Дендрологик парклар һәм ботан бакчалары табигатьне саклау учреждениеләре булалар, аларның вазыйфаларына үсемлекләр дөньясының күптөрлелеген саклап калу һәм аны баету, шулай ук фәнни, уку-укыту һәм мәгърифәт эшчәнлеген башкару максатларында, үсемлекләрнең махсус коллекцияләрен оештыру керә. Дендрологик парклар һәм ботан бакчаларының территорияләре бары тик

аларның турыдан-туры максатларын гамәлгә ашыру өчен генә билгеләнә, бу вакытта җир кишәрлекләре дендрологик паркларга, ботан бакчаларына, шулай ук карамакларында дендрологик парклар һәм ботан бакчалары булган фәнни-тикшеренү учреждениеләренә яисә мәгариф учреждениеләренә чикләнмәгән вакытка (даими) куллану өчен бирелә.

2. Дендрологик парклар һәм ботан бакчалары балансында булган йортлар, биналар, корылмалар хосусыйлаштырылмый.

3. Дендрологик парклар һәм ботан бакчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә тәэгеләләр.

65 статья. Дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар

1. Авыруларны дәвалау һәм профилактикалау, шулай ук халыкның ял итүен оештыру өчен яраклы һәм табигый дәвалау ресурсларына (шифалы сулар, дәвалау ләмнәре, дәвалаучы климат, коякта кызыну урыннары, акваторияләрнең өлешләре һәм башка табигать объектлары һәм шартлары) ия булган территорияләр (акваторияләр) дәвалау-сәламәтләндерү урыннарына кертелергә мөмкин.

2. Дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар, алардан нәтиҗәле файдалану һәм аларның табигый дәвалау ресурсларын, сәламәтләндерү үзлекләрен саклап калу максатларында, бүленеп алыналар.

3. Территорияләрне (акваторияләрне) дәвалау-сәламәтләндерү урыннарына һәм курортларга кертү законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Табигый дәвалау ресурслары булган, шулай ук, инфратезелмә объектларын да кертеп, алардан файдалану өчен биналары һәм корылмалары булган дәвалау-профилактика максатларында үзләштерелгән һәм кулланылучы территорияләр курортлар дип санала.

66 статья. Яшеллек зоналарын саклау

1. Шәһәрләр һәм башка торак пунктлары тирәсендә, мохитне саклау (әйләнә-тирә мохитне булдыру, экологик), санитария-гигиена һәм ял итү вазыйфаларын үтәүче, халыкның оешкан төстә һәм күпләп ял итүе, туризм өчен билгеләнүче территорияләр буларак, яшеллек зоналары, шул исәптән урман-парк саклау поялары тәэ-

лә.

2. Халык сәламәтлеге өчен аеруча әһәмияткә ия яшеллек зоналары дәүләт идарәсенең җирле күрсәтмәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән махсус саклanyлучы табигать территорияләренә кертелергә мөмкин.

3. Яшеллек зоналарында экологик, санитария-гигиена һәм ял итү вазыйфалары башкарылуга тискәре йогынты ясаучы хуҗалык эшчәнлеге алып бару тыела.

4. Яшеллек зоналарының чикләре һәм алардан файдалану режимы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

67 статья. Сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы булган үсемлекләрне һәм хайваннарны саклау

1. Сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы булган үсемлекләрне һәм хайваннарны саклау өчен Татарстан Республикасының Кызыл китабы булдырыла. Кызыл китапны алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланә торган нигезләмә белән билгеләнә.

2. Кызыл китапка кертелгән төрләргә керүче үсемлекләр һәм хайваннар һәр җирдә хуҗалыкта кулланудан алынырга тиеш. Мондый үсемлекләрнең һәм хайваннарның яшәү тирәлеген начарайтып, аларның санын киметүгә китерүче эшчәнлек алып бару тыела.

3. Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, җирдән башкача файдаланучылар Кызыл китапка кертелгән үз территорияләрендәге үсемлекләр һәм хайваннарның төрләрен саклау һәм ишәйтү буенча чаралар күрергә тиешләр.

## XI б ү л е к
## Экологик тикшерү

68 статья. Экологик тикшерү системасы һәм бурычлары

1. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә экологик тикшерү системасы әйләнә-тирә табигать мохитенең торышын күзәтү буенча дәүләт хезмәтеннән, дәүләт, житештерү һәм җәмәгатьчелек тикшерүеннән гыйбарәт.

152

2. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә тикшерү хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек йогынтысында әйләнә-тирә табигать мохитенең торышын һәм үзгәрүен күзәтүне, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, табигый байлыклардан нәтиҗәле файдалану, әйләнә-тирә табигать мохитен савыктыру буенча планнарның һәм гамәлләрнең үтәлешен тикшереп торуны, әйләнә-тирә табигать мохите сыйфатының нормативларын һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы законнарның таләпләрен үтәүне үз эченә ала.

69 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитенең торышын күзәтү буенча дәүләт хезмәте

1. Әйләнә-тирә табигать мохитенең торышын күзәтү һәм тикшерү буенча дәүләт хезмәте атмосфера һавасының, туфракның һәм су объектларының пычрану дәрәҗәсен һәм тиалеген, аларның кеше сәламәтлегенә, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына тискәре йогынтысын күзәтү, кызыксынучы оешмаларны һәм халыкны әйләнә-тирә табигать мохитендәге үзгәрешләр турында агымдагы һәм ашыгыч мәгълүматлар белән, әйләнә-тирә мохитнең торышы турында кисәтүләр һәм фаразлар белән бушлай тәэмин итү максатларында, министрлыклар, дәүләт комитетлары, ведомстволар тарафыннан оештырыла.

2. Әйләнә-тирә табигать мохитенең торышын күзәтү буенча дәүләт хезмәтен оештыру һәм аның эшчәнлеге тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый торган нигезләмә белән җайга салына.

70 статья. Дәүләт экология тикшерүе

1. Татарстан Республикасында дәүләт экология тикшерүе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле башка дәүләт органнары, тиешле хокук саклау органнары, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты тарафыннан үз вәкаләтлә-

ре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Үз вәкаләтләре чикләрендә дәүләт экология тикшерүен гамәлгә ашыручы органнарның урындагы затлары түбәндәгеләргә хаклы:

- милек рәвешләренә һәм кемгә буйсынуларына карамастан, билгеләнгән тәртиптә предприятиеләргә, оешмаларга, учреждениеләргә, хәрби частьләрне, Саклану министрлыгының махсус объектларын һәм хезмәтләрен, эчке эшләр һәм дәүләт иминлеге органнарын да кертеп, тоткарлыксыз керергә, үзләренең хезмәт вазыйфаларын үтәү өчен кирәкле әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау мәсьәләләренә бәйле документлар, анализлар, башка материаллар белән танышырга;

- житештерүләрне һәм технологик процессларны тикшерергә, технологик җайланмаларның, чистарткыч корылмаларның һәм зарарсызландыручы башка җайланмаларның эшен, аларны тикшереп тору чараларын, сыйфат нормативларының үтәлешен, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча планнарның һәм гамәлләрнең үтәлешен тикшерергә;

- зарарлы матдәләрне чыгарып ташлау һәм агызып чыгару, калдыкларны урнаштыру өчен рөхсәтләр бирергә;

- табигатьтән файдалану лицензияләрен килештерергә;

- табигатьтән файдалану өчен лимитлар билгеләргә;

- дәүләт экология экспертизасы билгеләргә, аның бәяләмәләренең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә;

- ачыкланган кимчелекләрне бетерүне таләп итәргә, бирелгән хокуклары чикләрендә, үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр яисә бәяләмәләр бирергә;

- гаепле затларны билгеләнгән тәртиптә административ җаваплылыкка тартырга, аларны дисциплинар, административ җаваплылыкка яисә җинаять җаваплылыгына җәлеп итү турында судка материаллар җибәрергә, табигатьне саклау турындагы законнарны бозып әйләнә-тирә табигать мохитенә яисә кешеләр сәламәтлегенә китерелгән зыянны түләттерү хакында гомуми судка дәгъва белдерергә;

- предприятиеләрнең, башка объектларның эшләрен һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерүче һәм кешеләр сәламәтлегенә ачыктан-ачык куркыныч тудыручы башка эшчәнлекләрен туктатып тору һәм бөтенләй туктату буенча эшләрне судка җибәрү ту-

рында карарлар чыгарырга.

3. Экология тикшерүе буенча дәүләт органнарының һәм урындагы әэтләрнең карарларына карата судка шикаять белдерелергә мөмкин.

71 статья. Житештерү экология тикшерүе

1. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә житештерү тикшерүе предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм аның максатлары барлык технологик процессларны табигать мохитен пычратуның үзләре өчен билгеләнгән күләмнәрен үтәгән килеш алып баруны тәэмин итүдән, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча, табигый байлыклардан нәтижәле файдалану, аларны ишәйтү, әйләнә-тирә табигать мохитен савыктыру буенча планнарның һәм гамәлләрнең үтәлешен, әйләнә-тирә табигать мохите сыйфатының нормативлары үтәлешен тикшерүдән гыйбарәт.

2. Житештерү тикшерүе органнарын оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты һәм, Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә министрлыгы белән килешенеп, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан расланә торган нигезләмәләр белән жайга салына.

72 статья. Жәмәгать экология тикшерүе

1. Жәмәгать экология тикшерүе жәмәгать органнары, гражданнар тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның максаты министрлыклар, дәүләт комитетлары, ведомстволар, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан әлеге Закон таләпләренең үтәлешен тикшереп торудан гыйбарәт.

2. Жәмәгать экология тикшерүен үткәрү тәртибе әлеге Закон һәм башка хокукый-норматив актлар белән жайга салына.

## XII б ү л е к
## Экологик тәрбия, белем, фәнни тикшеренүләр

**73 статья.** Экологик тәрбиянең һәм белемнең гомумилеге, комплекслылыгы һәм өзлексезлеге

Гомуми, комплекслы һәм өзлексез экологик белем системасы мәктәпкәчә һәм гомуми белем, һөнәр белеме, житәкче хезмәткәрләргә махсус экологик белем бирүне, профессиональ эколог-белгечләр әзерләүне, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге дәүләт органнары хезмәткәрләренең белгечлеген арттыруны, халыкны табигатьне саклау эшчәнлегенең төп нигезләмәләре һәм бурычлары белән таныштыруны, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча әерым эшчәнлеккә җәлеп итүне үз эченә ала.

**74 статья.** Уку йортларында экологик белем нигезләрен бирү

1. Гражданнарны экологик тәрбияләү өчен кирәкле минимум экологик белем, нинди юнәлештә булуына карамастан, экологик белем нигезләрен укыту юлы белән тәэмин ителә.

2. Юнәлешләренә карап, махсус урта һәм югары уку йортларында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалану буенча махсус курслар укыту күздә тотыла.

**75 статья.** Житәкче хезмәткәрләрнең һәм белгечләрнең һөнәри экологик әзерлеге

1. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнарының урындагы затлары һәм белгечләре махсус экологик белемгә ия булырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә табигать мохитенә һәм кешеләр сәламәтлегенә зарарлы йогынты ясаучы эшчәнлек белән бәйле министрлыклардагы, дәүләт комитетларындагы, ведомстволардагы, предприятиеләрдәге, учреждениеләрдәге һәм оешмаларда урындагы затларның һәм белгечләрнең экологик әзерлеге булырга тиеш, ул хезмәткәрләрне урындагы хезмәткә билгеләгәндә, аттестацияләгәндә һәм кабат аттестацияләгәндә исәпкә алына.

3. Кирәкле әзерлеге булмаган затлар тиешле экологик белемне таләп итә торган эшләрне башкара алмыйлар.

76 статья. Фәнни экологик тикшеренүләр

1. Татарстан Фәннәр академиясе, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча, мәгариф буенча дәүләт органнары, министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар, фәнни учреждениеләр, югары уку йортлары әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм савыктыру, табигатьтән нәтиҗәле файдалану һәм табигый байлыкларны ишәйтү өлкәсендә комплекслы программалар һәм фәнни тикшеренү планнары әзерлиләр һәм раслыйлар, нәтиҗәле экологик тикшеренүләр һәм алынган нәтиҗәләрне тормышка ашыру өчен кирәкле шартлар тудыралар.

2. Фәнни учреждениеләрнең һәм табигатьне саклау оешмаларының галимнәре һәм белгечләре комплекслы, максатчыл экологик программаларны (республика, төбәк программаларын) әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда, проект эшләрендә катнашалар, фәнни-техник һәм эксперт советлары составларына керәләр, проектларга экологик экспертиза буенча бәяләмәләр бирәләр, җәмгыятьне экологик тәрбияләүне оештыруда катнашалар һәм үз эшләнмәләренең фәнни нәтиҗәләре өчен шәхси җаваплы булалар.

XIII б ү л е к
Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау
өлкәсендәге бәхәсләрне хәл итү

77 статья. Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар арасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге бәхәсләрне хәл итү

Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, гражданнар арасында әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

## XIУ б ү л е к
## Экологик хокук бозулар өчен җаваплылык

78 статья. Экологик хокук бозулар өчен җаваплылык

Табигатьне саклау турындагы законнарны бозып, әйләнә-тирә табигать мохитенә һәм кешеләр сәламәтлегенә зыян китергән өчен предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, урындагы затлар, гражданнар законнар нигезендә җаваплы булалар.

79 статья. Экологик хокук бозулардан килгән зыянны түләттерү

Әйләнә-тирә табигать мохитен пычратып, табигый байлыкларны бозып, юкка чыгарып, зарарлап, аларны урынсыз файдаланып, табигый экологик системаларны бозып һәм башка экологик хокук бозулар белән әйләнә-тирә табигать мохитенә, гражданнарның сәламәтлегенә һәм малкатенә, башка предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның милкенә зыян китергән предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар законнарда билгеләнгән тәртиптә зыянны тулысынча түләргә тиешләр.

## XV бүлек. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек

80 статья. Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының халыкара хезмәттәшлеге принциплары

Татарстан Республикасы түбәндәге принциплар нигезендә әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә халыкара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра:

- халыкара хокук нормаларын үтәү, кешенең сәламәт һәм уңайлы әйләнә-тирә табигать мохитенә хокукларын, дәүләтләрнең үз карамагы чикләрендәге әйләнә-тирә табигать мохитен, табигый байлыкларны саклауга һәм алардан файдалануга хокукларын тану;
- экологик иминлекне тәэмин итүдә һәм Җир табигатен саклауда гомум кешелек хезмәтләренең өстенлеге;

158

- әйләнә-тирә табигать мохите турында һәм андагы үзгәрешләр, һәлакәтләр, бәла-казалар һәм табигатьне саклаучы алдынгы технологияләр турында мәгълүматлар алмашу;

- әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча халыкара йөкләмәләрне үтәү;

- гадәттән тыш экологик вәзгыятьләрдә бер-беренә ярдәм итү.

<u>81 статья.</u> Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә халыкара шартнамәләр

Әгәр әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән халыкара шартнамәдә әлеге Законда каралмаган башка кагыйдәләр билгеләнгән булса, ул чакта халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

<u>82 статья.</u> Татарстан Республикасының халыкара экологик программалар әзерләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда катнашуы

Татарстан Республикасы әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча халыкара оешмаларның эшчәнлегендә, халыкара конференцияләр әзерләүдә һәм үздыруда, халыкара экологик программалар әзерләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда катнаша, әйләнә-тирә табигать мохите өлкәсендә белгечләрнең делегацияләрен алмаша.

<u>83 статья.</u> Табигатьне саклау турындагы Татарстан Республикасы законнарын үтәү буенча чит ил юридик һәм физик затларының, гражданлыгы булмаган затларның бурычлары

Чит ил юридик затлары һәм физик затлары, гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасы территориясендә әлеге Закон һәм табигатьне саклау турындагы башка закон актлары таләпләрен үтәргә тиешләр һәм аларны бозган өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

Татарстан Республикасы
Президенты

М. .Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 12 феврале
N 1040